СОВЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 23, с. Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 23 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366)3-92-40, факс (84366)3-92-40. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**
**Апаз авыл җирлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**“ 01 ” ноябрь 2024 ел** **№ 11**

**Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Кзыл-Игенче авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегенең Кзыл-Игенче авылы, Дальняя урамы, 3 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 16 ноябренә 10 сәгать 00 минутта халык җыенының билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2025 елда Апаз авыл җирлеге Кзыл-Игенче авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, түләү күләме 3000 сум тәшкил иткән үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу; Кзыл-Игенче авылының Дальняя урамыннан Пөшәңгәр авылының Нагорная урамына кадәрге җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлын ташлы балчык, вак таш җәеп тигезләү, бишенче этабы; Кзыл-Игенче авылының Дальняя урамында автомобиль юлын тигезләү өчен вак таш җәю);

- янгынга каршы резервуарлар (янгынга каршы су җыю урыннары), янгын пирслары ясау, ремонтлау (янгынга каршы ёмкостька электр насосы сатып алу һәм урнаштыру);

- коймалар кору, күмү урыннарын төзекләндерү (инвентарь саклый торган зират өен тышлау)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ""

3. "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегенең Кзыл-Игенче авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 13 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Кзыл-Игенче авылы, Дальняя урамы, 16 йорт адреслары буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Котдусов

СОВЕТ АПАЗОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609003056